**Татар телендә гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры биремнәре *җаваплары***
**2021-2022 нче уку елы**
**4 нче сыйныф**

**Максималь балл – 33**

## I. Тестны эшләгез.

1. Татар телендә генә булган тартык авазларны билгеләгез. **(1 балл)**

а) [в]

**ә) [к]**

**б) [ж]**

в) [н]

2. Калын һәм нечкә сузыкларның парлары дөрес бирелмәгән вариантны билгеләгез. **(1 балл)**

а) [а] – [ә]

ә) [у] – [ү]

**б) [ы] – [и]**

в) [о] – [ө]

3. Сүзнең транскрипциясендә хата булган вариантны билгеләгез. **(1 балл)**

а) болын – [болон]

**ә) колын – [колон]**

б) төлке – [төлкө]

в) көлке – [көлкө]

4. Басым сүзнең соңгы иҗегенә төшмәгән сүзне билгеләгез. **(1 балл)**

**а) татарча**

ә) китаплар

б) бакчабыз

в) сүзлектә

5. Алынма сүзләрне билгеләгез. **(1 балл)**

**а) дәрес**

ә) укучы

б) сүзлек

**в) эшләпә**

6. Омонимнарны билгеләгез. **(1 балл)**

**а) карт аю – картаю**

**ә) төш күрдем – төш җитте**

б) матур көн – чибәр кыз

в) зур өстәл – кечкенә урындык

7. Сингармонизм законына буйсынмый торган сүзне билгеләгез. **(1 балл)**

а) төлке

ә) иртә

б) салкын

**в) мисал**

8. Составында сүз ясагыч кушымча булган сүзне билгеләгез. **(1 балл)**

а) апага

ә) бүреләр

**б) күзлек**

в) урамым

9. Сүз төзелешен тикшергәндә киткән хатаны билгеләгез. **(1 балл)**

балыкчылар

а) балык – тамыр

ә) -чы – сүз ясагыч кушымча

**б) -лар – сүз ясагыч кушымча**

в) балыкчы – нигез

10. Су сүзенә тамырдаш булган сүзләрне билгеләгез. **(1 балл)**

**а) сулык**

ә) суган

**б) сулы**

**в) сусыл**

## II. Теоретик бирем. (5 балл)

Сүзләрнең туры һәм күчерелмә мәгънәләре турында языгыз. Өчәр мисал китерегез.

Сүзләр әйберләрнең төп мәгънәсен белдерсә, туры мәгънәдә (бала елмая), төп мәгънәсен белдермәсә, күчерелмә мәгънәдә (чәчәк елмая) була.

кайнар су – кайнар сәлам

авыр йөк – авыр кайгы

якты йөз – якты йолдыз

## III. Гамәли-иҗади бирем. (15 балл)

1. Шигъри юлларны, төшеп калган хәрефләрен куеп, күчереп языгыз.

***(3 балл: бер хәреф – 0,5 б.)***

Йолд**ы**злар төш**е**п кушылган
Чыршыдагы утларга.
Кыш бабай белән Кар кызы
Килгән безн**е** котларга.

Яңа елны**ң** бә**х**етле ел
Буласын без беләбез.
Шу**ң**а күрә бергәләшеп
Яңа елга керәбез!

Роберт Миңнуллин

2. Басым соңгы иҗеккә төшмәгән сүзләрне күчереп языгыз. ***(1 балл)***
*беләбез, керәбез*

3. Ел сүзенә язмача фонетик анализ ясагыз. ***(4 балл)***

Ел [йыл]

Ел: ел.

Хәрефләр: е, л.

Авазлар:

[й] – яңгырау тартык аваз,

[ы] – калын сузык аваз,

[л] – яңгырау тартык аваз.

___________

2 х., 3 ав.

4. Кыш бабайга хат языгыз. (7-10 җөмлә) ***(10 балл)***

**Татар телендә гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры биремнәре *җаваплары***
**2021-2022 нче уку елы**
**5 нче сыйныф**

**Максималь балл – 45**

**I. Тестны эшләгез. (10 балл)**

1. Фонетика нәрсәне өйрәнә? ***(1 балл)***

а) сүз ясалышын

ә) сүз байлыгын

**б) сөйләм авазларын**

в) сүз төзелешен

2. Татар телендә ничә сузык аваз бар? ***(1 балл)***

а) 9

ә) 13

**б) 12**

в) 6

3. Сүзнең транскрипциясендә хата булган вариантны билгеләгез. ***(1 балл)***

а) [сөлгө]

ә) [борон]

б) [болот]

в) **[қөзгө]**

4. Мәкальнең дәвамын билгеләгез. ***(1 балл)***

Үзең сөйли башлаганчы,

а) кеше сүзен тыңлап торма.

**ә) кеше сүзен тыңлап бетер.**

б) аның сүзен тыңлама.

в) кеше сүзен бүлдереп тор.

5. Татар телендә ничә тартык аваз бар? ***(1 балл)***

**а) 28**

ә) 24

б) 20

в) 12

6. Татар телендәге кыска сузыклар рәтен билгеләгез. ***(1 балл)***

а) а, ә, о, ы

ә) о, ы, ү, и

**б) о, ы, е, ө**

в) ә, ы, у, о

7. *Карт төлке* фразеологизмын башка бер сүз белән алыштырыгыз. ***(1 балл)***

а) акыллы

**ә) хәйләкәр**

б) ялкау

в) тынгысыз

.

8. Орфография нәрсәне өйрәнә? ***(1 балл)***

а) сүзләрнең дөрес әйтелешен

ә) сөйләм авазларын

б) сүз төзелешен

**в) дөрес язу кагыйдәләрен**

9. Искергән сүзне билгеләгез. ***(1 балл)***

а) бәхет

**ә) гакыл**

б) туган

в) гасыр

10. Сыйфатлар рәтен табыгыз ***(1 балл)***

а) эреләт, яшелләт, матурлан

ә) сызык, килен, белем

**б) хәрәкәтчән, уйчан, сакчыл**

в) татарча, русча, инглизчә

## II. Теоретик бирем

Омонимнар һәм аларның төрләре турында языгыз. Һәр төренә икешәр мисал китерегез. **(8 балл)**

Әйтелешләре һәм язылышлары бер үк, әмма мәгънәләре арасында уртаклык булмаган сүзләр **омонимнар** дип йөртелә. Омонимнарның дүрт төре бар.

**Саф лексик омонимнар** – аваз составы ягыннан бер-берсенә охшаш тамыр сүзләр: *туп, ат.*

**Омофоннар** – әйтелешләре бер, язылышлары төрле булган сүзләр: *сыер чык, сыерчык; карт аю, картаю.*

**Омографлар** – язылышлары бер, әйтелешләре төрле булган сүзләр: *басмá, бáсма; алмá, áлма.*

**Омоформалар** – бер грамматик формада гына омоним булган сүзләр: *күркәм* – сыйфат *(красивый), күркәм* – исем *(мой индюк); өй* – исем *(дом), өй* – боерык фигыль *(сложи в кучу)*.

## III. Гамәли-иҗади бирем (27 балл)

1. Төшеп калган хәрефләрне куеп, текстны күчереп языгыз. **(3 балл: бер хәреф – 0,3 б.)**

Көз

Дөн**ья** тынып калды. Көз килде дә ка**е**н я**ф**ракларын сап-сары бу**я**уга манды. Ә көзге җил минем дустымны селкетте. Аның сары яфраклары җиргә коелды. Бу көннәрдә кошлар да ерак-ерак илләргә киттеләр. Каен агачы я**п**-ялang**а**ч торып калды. Аңа бик салкын булыр инде.

Ә мин борч**ы**лмыйм. Тиздән ак ту**н** кигән Кыш бабай килер. Ул җирне ап-ак ю**р**ган белән капл**а**р.

Нәби Дәүлидән

1. ***Каен*** сүзенә язмача фонетик анализ ясагыз. **(6 балл)**

Каен **[**қ а° й ы́ н**]**

Ка-ен

Хәрефләр: к, а, е, н.

Авазлар:

**[**қ**]** – саңгырау тартык аваз, яңгырау пары [ғ],

[а°] – калын сузык аваз,

[й] – парсыз яңгырау тартык аваз,

[ы] – калын сузык аваз,

[н] – парсыз яңгырау тартык аваз.

__________

4 х., 5 ав.

2. ***Күзге, кошлар*** сүзләрен мәгънәле кисәкләргә таркатыгыз. **(2 балл)**

Күз (тамыр) - ге (сыйфат ясагыч кушымча); кош (тамыр) - лар (форма ясагыч кушымча (яки модальлек кушымчасы)

3. ***Баш*** сүзенннән биш тамырдаш сүз ясап языгыз. **(5 балл)**

Юл - юллы, юлсыз, юлчы, юлдаш, юллык (юллау, юлдашсыз).

4. ***Ману, селкетү*** сүзләренең синонимнарын языгыз. **(1 балл)**

Ману - буяу; селкетү - тирбәтү.

5. “Ак тун кигән Кыш бабай” темасына 9-10 җөмләдән торган бәйләнешле текст төзеп языгыз. **(10 балл)**

**Татар телендә гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры биремнәре *җаваплары***
**2021-2022 нче уку елы**
**6 нчы сыйныф**

**Максималь балл – 48**

## I. Тестны эшләгез. (10 балл)

1. Нәрсә ул аваз? (**1 балл**)

а) авазларның язудагы билгесе

**ә) сөйләмнең бүленми торган иң кечкенә кисәге**

б) авазларның охшашлануы

в) сузык аваз төшеп калу яки кыскару

2. Ясалу урыны буенча **[й]** тартыгы – (**1 балл**)

а) тел алды тартыгы

ә) йоткылык тартыгы

б) **тел уртасы тартыгы**

в) ирен-ирен тартыгы

3. *Кое* сүзендә е хәрефе ничек укыла? (**1 балл**)

а) [й ы]

ә) **[й о]**

б) [й ө]

в) [й е]

4. Тулы редукция күренешенә караган мисалны табыгыз. (**1 балл**)

а) кеше

ә) борын

**б) борыны**

в) урын

5. Борын ассимиляциясенә караган мисалны табыгыз. (**1 балл**)

а) эштә

ә) көнбагыш

**б) төннәр**

в) унбер

6. *Курку* сүзенең синонимын табыгыз. (**1 балл**)

а) янау

ә) гөрләү

**б) шүрләү**

в) күнү

7. *Җанын кая куярга белми* фразеологизмын башка бер сүз белән алыштырыгыз. (**1 балл**)

а) иркәли

ә) **кайгыра**

б) шатлана

в) уйлый

.

8. Диалекталь сүзләр булган рәтне табыгыз. (**1 балл**)

а) аю, акыл, җиһан

ә) канәгать, дөнья, мал

б) әти, әби, әтәч

**в) этәй, әбәй, кучат**

9. *Арыш, өстәл, сохари, уҗым* сүзләре (**1 балл**)

а) **рус алынмалары**

ә) гарәп-фарсы алынмалары

б) гомумтөрки сүзләр

в) һинд, кытай алынмалары

10. Кушымчалау юлы белән кайсы сүзләр ясалалар? (**1 балл**)

а) **ясалма сүзләр**

ә) кыскартылма сүзләр

б) парлы сүзләр

в) кушма һәм парлы, тезмә сүзләр

## II. Теоретик бирем (8 балл)

Диалектизмнар турында языгыз һәм мисаллар китерегез.

**Диалектизм** дип билгеле бер территориядә генә таралган, әдәби телдә кулланылмый торган тел үзенчәлекләрен атыйлар. Билгеле бер территориядә яшәүче кешеләр аралашуында кулланыла торган сөйләм **сөйләш** дип

йөртелә. Шул төбәктә генә кулланыла торган сүзләрне **диалекталь сүзләр** дип йөртәләр: *әтәй (әти), әбәй (әби), кучат (әтәч), тутырык (тулы), кузганак (кузгалак), тоснак (тоткын), көлчә (ка- бартма).*

**Диалектология** – диалектларны өйрәнә торган фән. Татар теленең өч диалекты бар: 1) урта диалект; 2) көнбатыш диалект; 3) көнчыгыш диалект.

## III. Гамәли-иҗади бирем (30 балл)

Хөсәеннең катыны Гайшә өстәл җыештырып маташа, Мостафа арлы-бирле йөри иде. Хөсәен чыгып китте.

Тышта буранның сызгыруы белән стенадагы сәгать тыкылдавыннан башка, өй эчендәге тынлыкны бернәрсә дә бозмый, тик бишектә йоклаган баланың ара-тирә көрсенүе генә ишетелә иде.

– Көн бик начар, – диде Гайшә.

– Сез һәммәгез дә шулай?

– Ничек?

– Бала өчен газапланасыз.

– Бар дөньяң шул бала өчен.

– Әмма бала усал! – диде Мостафа һәм ашыга-ашыга киенә башлады. Ул ике тәрәзә арасындагы көзге турысына килде. Башлыгының очларын алдан әйләндереп, артка бәйләп маташты. Ул тагын:

– Бала усал, – диде. Бу юлы ул шул сүзләре белән Гайшәгә нидер сөйләмәкче иде, ишектән Хөсәен керде һәм:

– Иптәш, ат хәзер! – диде.

Ш. Камалдан

1. ***Көзге*** сүзенә фонетик анализ ясагыз. **(6 балл)**

**Көзге [к ө з г ө́]**

Көз-ге

Х ә р е ф л ә р: к, ө, з, г, е.

А в а з л а р:

[к] – саңгырау тартык аваз, яңгырау пары [г], тел арты тартыгы;

[ө] – алгы рәт, кыска, иренләшкән сузык аваз;

[з] – яңгырау тартык аваз, саңгырау пары – [с], тел алды тартыгы;

[г] – яңгырау тартык аваз, саңгырау пары – [к], тел алды тартыгы;

[ө] – алгы рәт, кыска, иренләшкән сузык аваз.

---

5 х., 5 ав.

2. ***Юлдашлар*** сүзен сүз төзелеше ягыннан тикшерегез. **(5 балл)**

*Юл* – тамыр, тамырдаш сүзләр: *юлчы, юлдаш*; -даш – сүз ясагыч кушымча (исем ясагыч кушымча); -лар – форма ясагыч кушымча (яки модальлек); *юлдаш* – ясалма нигез.

3. *Хөсәеннең* ***катыны*** *Гайшә өстәл җыештырып маташа, Мостафа арлы-бирле йөри иде* дигән җөмләдә *катыны* сүзе кулланылыш сферасы ягыннан кайсы төркемгә карый? **(2 балл)**

Катыны – хатыны, диалекталь сүз.

4. ***Ашыгу*** сүзенең дүрт синонимын языгыз. **(4 балл)**

**Ашыгу –** кабалану, өтәләнү, кызулану, тизләү (каударлану)

5. "*Ана күңеле баладa, бала күңеле далада*" дигән темага 12-13 җөмләдән торган бәйләнешле текст төзеп языгыз. **(13 балл)**

**Татар телендә гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры биремнәре *җаваплары***
**2021-2022 нче уку елы**
**7 нче сыйныф**

**Максималь балл – 50**

## I. Тестны эшләгез. (10 балл)

1. Сузыкларның калынлыкта яки нечкәлектә ярашуы нәрсә ул? (**1 балл**)

а) авазлар охшашлану

**ә) рәт гармониясе**

б) аваз кыскару

в) иренләшү гармониясе

2. Иренләшкән сузык авазны табыгыз. (**1 балл**)

**а) [о]**

ә) [ы]

б) [и]

в) [э]

3. *Көе* сүзендә е хәрефе ничек укыла? (**1 балл**)

а) [й ы]

ә) [й о]

б) **[й ө]**

в) [й е]

4. Позицион аваз үзгәрешләренә нәрсә керә? (**1 балл**)

а) ассимиляция

ә) аккомодация

**б) редукция күренеше**

в) дөрес язу кагыйдәләре

5. Алдан [й] яки [w] авазы, аннан соң сузык аваз килсә, (**1 балл**)

**а) бу күтәрелмә дифтонг дип атала**

ә) төшерелмә дифтонг дип атала

б) трифтонглар дип атала

в) иренләшү гармониясе була

6. Ойконимия фәне нәрсәне өйрәнә? (**1 балл**)

а) географик атамаларны

ә) кеше исемнәрен

**б) авыл, шәһәр, торак пункт исемнәрен**

в) сулык атамаларын

7. *Кататься как сыр в масле* фразеологизмының татар телендәге тәрҗемәсен табыгыз. (**1 балл**)

а) баштан чыкмау

ә) иренендә сөт кипмәү

б) телне йоту

**в) авыз балда-майда**

8. Күчерелмә мәгънәдәге сүзләрне табыгыз. (**1 балл**)

а) алтын балдак

ә) җил исә

**б) җил елый**

в) авыр сумка

9. *Кайтаваз* сүзенең синонимын табыгыз. (**1 балл**)

а) кычкыру

**ә) яңгыравык**

б) үкерү

в) акыру

10. Антропонимика нәрсәне өйрәнә? (**1 балл**)

а) күк җисемнәре атамаларын

ә) хайван кушаматларын

**б) кеше исемнәрен, кушамат, фамилияләрне**

в) географик объект атамаларын

## II. Теоретик бирем (15 балл)

**Антонимнар һәм аларның төрләре турында языгыз һәм мисаллар китерегез.**

Капма-каршы мәгънәле сүзләр антонимнар дип атала: әйе — юк, көн — төн, озын — кыска, ата — ана, ак — кара, ачы — татлы.

Сөйләмдә кулланылышлары ягыннан антонимнарны тел антонимнарына һәм контекстуаль антонимнарга бүлеп йөртәләр.

**Тел антонимнары** сүзнең төп мәгънәләре буенча капма-каршы булалар: Ачның хәлен тук белмәс.

**Контекстуаль антонимнар** контекстта гына антоним булып киләләр. Аерым торганда, алар антоним булудан туктый: Башын югары күтәреп, Хәмис каршына торып басты. Болай басканда буй да бераз үскән, курку да кимегән.

Антонимнар ярдәмендә парлы сүзләр дә ясала: ут-су, яз-көз, дус-дошман, көн-төн, ата-ана, аклы-каралы.

**III. Гамәли-иҗади бирем (25 балл)**

Айдар иң рәнҗетелгән, иң кыйналган малай булгандыр инде, аның белән дуслашырга теләүче юк. Дөресен генә әйткәндә, Хәмистән куркалар, качалар. Ләкин Айдарның бер иптәше бар. Ул — ятимнәр йортының мал абзарында яшәүче Кызылканат кушаматлы ат, аның якын дусты. Бу йорттагы бөтен хуҗалык эшләрен шул ат башкара, шул ат эшли. Ни өчен Кызылканатмы? Кып-кызыл төстә ул. Чапканда озын яллары ике якка таралып, җилфердәп китә! Чын канатлар кебек, җилфер-җилфер килә.

Айдар бүген дә ат янына керәчәк, печән салачак, су китерәчәк, ялын тарап куячак. Аңа ятимнәр йортындагы яңалыкларны сөйләячәк. Әлбәттә, туган көне булмавы хакында да әйтәчәк ул Кызылканатка.

Г. Гыйльмановтан

1. ***Ятим*** сүзенә фонетик анализ ясагыз. **(5 балл)**

**Ятим [й ә т и́ м]**

Я - тим

Х ә р е ф л ә р: я, т, и, м

А в а з л а р:

[й] — парсыз яңгырау тартык аваз, сонор, тел уртасы тартыгы;

[ә] — алгы рәт, озын, иренләшмәгән сузык аваз;

[т] — саңгырау тартык аваз, яңгырау пары — [д], тел алды тартыгы;

[и] — алгы рәт, озын, иренләшмәгән сузык аваз;

[м] — парсыз яңгырау тартык аваз, сонор, ирен-ирен тартыгы, борын авазы;

---

4 х., 5 ав.

2. *Кызылканат* сүзе ничек ясалган? Ясалышы ягыннан ул нинди сүз? **(2 балл)**

*Кызыл* һәм *канат* сүзләрен кушу юлы белән ясалган, кушма сүз.

3. *Җилфердәү* сүзенең синонимнарын языгыз. **(4 балл)**

**Җилфердәү -** чайкалу, тибрәнү, җилфер-филфер килү (итү), селкенү.

4. Җөмләне татар теленә хас булган тәртиптә үзгәртеп языгыз. (**2 балл**)

Әлбәттә, туган көне булмавы хакында да әйтәчәк ул Кызылканатка.

Әлбәттә, туган көне булмавы хакында да ул Кызылканатка әйтәчәк.

5. *"Яшьтәшләрең белән ничек дуслашасың?"* дигән сорауга җавап итеп, 11-12 җөмләдән торган бәйләнешле текст төзеп языгыз. **(12 балл)**

**Татар телендә гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры биремнәре *җаваплары* 2021-2022 нче уку елы 8 нче сыйныф**

**Максималь балл – 55**

## I. Тестларны эшләгез. (10 балл)

1. Рәт гармониясенә буйсынган сүзләр рәтен тап. (**1 балл**)

а) җиһан, укучы, көнбатыш

**ә) агачлар, атлар, ятимнәр**

б) төньяк, суык, тимераяк

в) миңа, мисал, китап

2. Әдәби әйтелешне бозып сөйләүнең сәбәбен билгелә. (**1 балл**)

а) гел чит телдә сөйләшү

ә) басымны дөрес куймау

б) сүзләрне дөрес язмау

в) **әдәби әйтелеш белән дөрес язылыш арасында аерма булу**

3. Кайсы сөйләштә **[з]** тартыгын сакаулаштырып әйтәләр? (**1 балл**)

а) көнчыгыш диалектта

**ә) минзәлә сөйләшендә**

б) урта диалектта

в) көнбатыш диалектта

4. Морфологик принцип ул – (**1 балл**)

а) сүзләрнең элекке язылышын саклап язу

ә) ишетелгәнчә язу

б) рус теленнән һәм рус теле аша кергән сүзләрне рус телендәгечә язу

в) **сүзләрнең мәгънәле кисәкләрен һәр очракта да бер генә төрле язу**

5. Кайсы диалектта сүзләрне **Җ** -ләштереп әйтәләр? (**1 балл**)

а) көнчыгыш диалектта

ә) минзәлә сөйләшендә

**б) урта диалектта**

в) көнбатыш диалектта

6. Кайсы рәттәге сүзләрдә **h** хәрефе языла? (**1 балл**)

а) пө...тә, ...ат, рә...әт, ...алык

ә) шә...әр, ...әлак, ...ыял, ә...әмият

**б) һава, зинһар, даһи, һәйкәл**

в) ...өнәр ,...әтер, тари..., ил...ам

7. Гомумтөрки сүзләр булган рәтне билгеләгез. (**1 балл**)

**а) сары, биш, күз**

ә) имтихан, рөхсәт, дәфтәр

б) кәгазь, армия, почта

в) дару, рәсем, җиһан

.

8. Сыйфат сүз төркеме нәрсәләр белән төрләнә? (**1 балл**)

а) зат-сан

ә) заман

б) барлык-юклык

**в) дәрәҗә**

9. *Сизгер* сүзенең синонимын табыгыз. (**1 балл**)

а) елгыр

**ә) уяу**

б) җитез

в) сихри

10. *Барыйм, барыйк* фигыльләре кайсы фигыль төркемчәсенә карый? (**1 балл**)

а) хикәя фигыль

**ә) теләк фигыль**

б) боерык фигыль

в) шарт фигыль

## II. Теоретик бирем (14 балл)

**Сыйфат фигыль турында языгыз һәм мисаллар белән аңлатыгыз.**

Сыйфат фигыль – сыйфат һәм фигыль билгеләрен берләштергән затланышсыз фигыль төркемчәсе. Аның өч заман формасы була.

1) Хәзерге заман сыйфат фигыль (-учы/-үче; -а/-ә, ый/-и + торган ярдәмче фигыле): фамилиясен алыштыручы (кеше), авырмый торган (егет). -учы/-үче формалы сыйфат фигыль сыйфатланмышы төшеп калганда исемләшә һәм килеш, сан, тартым белән төрләнә: фамилиясен алыштыручылар бар, шушы фамилияне йөртүчене эзләделәр. Кайбер сыйфат фигыльләр исемгә күчкәннәр: сатучы, очучы, язучы, укытучы;

2) Үткән заман сыйфат фигыль (-ган/-гән, -кан/-кән): сөенечтән типкән (йөрәк), шатланган (Самат). Үткән заман сыйфат фигыль сыйфатланмышы төшеп калганда исемләшә һәм килеш, сан, тартым белән төрләнә: шатланганын күрделәр, кайтканда безгә кер;

3) киләчәк заман сыйфат фигыль (-ачак/-әчәк, -ячак/- ячәк; -ар/-әр, -ыр/-ер, -р; -асы/-әсе, -ыйсы/-исе). Киләчәк заман сыйфат фигыльнең -асы/-әсе, ыйсы/-исе формасы исемләшә: әйтәсе (сүз), әйтәселәр әйтелде. Бу сыйфат фигыльнең юклык төре булмый.

## III. Гамәли-иҗади бирем (31 балл)

Карчык тавыкларга җим ясап тора иде, хат ташучы килеп керде. Хатны кулына алды да аптырап калды. Катлы-катлы кәгазь ябыштырылган хатка карап торды да агарып китте. Оныгының дәфтәр битенә язган хатын күргәч, йөрәген ниндидер хәвеф-хәтәр ярып узды. «ДӘҮ ӘНИ! Яратам, кил, кил, кил, кил! Айзадә».

– И Айзадә, ниләр булды икән сиңа, балакаем? – дип, өйгә кереп китте.

– Ни булды, карчык, – диде Галихан.

– Айзадәгә нидер булган! Әйтәм аны хатлары, хәбәрләре юк...

Карт та «кил, кил» дип язылганга озак карап торды. Аның маңгае, җыерчыклы йөзе тагын да каралып китте. Озак кына сүзсез торгангач:

– Карчык, җыен, Казанга китәбез – дип, өйгә кереп китте.

Р. Шәйдуллина-Мураттан

1. *Хәвеф-хәтәр* сүзенең мәгънәсен аңлатыгыз. (**3 балл**)

**Хәвеф-хәтәр** – курку хисе, куркыныч янау. Хәвефләнү, борчылу, шикләнү.

2. Тексттан сыйфат фигыльләр булган җөмләләрне күчереп языгыз, сыйфат фигыльләрнең заманнарын билгеләгез. **(4 балл)**

1) Катлы-катлы кәгазь **ябыштырылган** хатка карап торды да агарып китте. Ябыштырылган (хат) – үткән заман сыйфат фигыль.

2) Карт та «кил, кил» дип **язылганга** озак карап торды.

Язылганга – язылган (хатка), исемләшкән үткән заман сыйфат фигыль, юнәлеш килешендә.

3. Сүзләрнең антонимнарын языгыз. **(4 балл:** *һәр җавапка 0,5 балл***)**

Кил – кит, файдалы – зарарлы, пышылдап – кычкырып, саран – юмарт, тәрбияле – тупас, тиз – озак, сай – тирән, шикәр – тоз.

4. Текстны укы. Татар теленә башка телләрдән кергән сүзләрне (алынма сүзләрне) язып ал. (**5 балл:** *һәр сүзгә 0,5 балл*)

Картлар өйгә керделәр. Галихан бабай, ишек янындагы сумкасын күтәреп, Зифа әби белән кухняга юнәлде. – Менә, Асия, аз гына авыл күчтәнәче бар иде, авыз итәрсең, – дип, карт бер литрлы банка белән балны, каклаган каз, каймак, варенье, китап битенә төргән йомыркаларны өстәлгә куйды.

Р. Шәйдуллина-Мураттан

**Алынма сүзләр:** Галихан, сумкасын, Зифа, кухняга, Асия, литрлы, банка, варенье, китап, өстәлгә.

5. “Заманча аралашу чаралары” дигән темага 14-15 җөмләдән торган бәйләнешле текст төзеп языгыз. **(15 балл)**

**Татар телендә гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры биремнәре *җаваплары* 2021-2022 нче уку елы 9 нчы сыйныф**

**Максималь балл – 43**

**I. Тестны эшләгез.**

1. Татар телендә ничә сузык аваз бар? **(1 балл)**

**а) 12**

ә) 9

б) 6

в) 5

2. Трифтонг булган сүзне билгеләгез. **(1 балл)**

а) йолдыз

ә) тау

**б) яулык**

в) бабай

3. Саңгырау тартыклар гына булган сүзне билгеләгез. **(1 балл)**

а) якты

ә) хәреф

б) болын

**в) чәчәк**

4. Мәкальнең дәвамын билгеләгез. **(1 балл)**

Бу көнге эшен иртәгә калдырган кешенең

а) бер кат эшләп күрсәт.

ә) кыю эшкә йөрәк бар.

**б) эше һич бетмәс.**

в) бетерә бел.

5. Йомык тартыкларны билгеләгез. **(1 балл)**

**а) [т]**

ә) [н]

**б) [г]**

в) [ғ]

6. Мәкальдән ярымйомык тартыклар гына булган сүзне табып языгыз.

**(1 балл)**

*Аннан-моннан эшләсәң, яңадан эшләрсең.*

*Аннан-моннан*

7. Ирен-ирен тартыгын билгеләгез. **(1 балл)**

**а) [м]**

ә) [к]

б) [в]

в) [й]

8. Тулы редукция күзәтелгән сүзне билгеләгез. **(1 балл)**

а) сеңел

ә) авыру

б) борыны

**в) холкы**

9. *кашыгаяк* сүзенең әдәби телдәге синонимын билгеләгез. **(1 балл)**

а) аяк

**ә) савыт-саба**

б) кашык

в) бөҗәк

10. Архаизмны билгеләгез. **(1 балл)**

а)солтан

ә) чабата

**б) сала**

в) алпавыт

## II. Теоретик бирем (4 балл)

Неологизмнар турында языгыз (нинди сүзләр, ни өчен барлыкка киләләр һ. б.). 6 мисал китерегез. **(4 балл: *1 балл кагыйдә өчен, 0,5 әр балл мисалларга*)**

Неологизмнар – аерым бер чорда яңа күренеш, төшенчәләрне атау өчен телдә барлыкка килгән сүзләр: *глобаль челтәр, электрон почта, инвестор, инфраструктура, лизинг, риэлтор, чартер* һ.б. Яңа сүзләр мәгълүмат чаралары телендә чагылыш таба һәм, акрынлап, актив лексикага, гомумкулланышка кереп китә.

## III. Гамәли-иҗади бирем. (29 балл)

Туган телемә

Асыл сүзләреңне, туган телем,
Биреп торчы миңа азга гына.
Бөтенләйгә түгел – вакытлыча,
Тик җитәрлек гомер азагыма.

Синнән алган һәрбер сүземне мин
Күз карасы кебек саклар идем.
Ул сүзләрнең затлыларын сайлап,
Дога итеп кенә ятлар идем.

Ул сүзләрем җырларга әйләнгәч,
Мин кайтарып сиңа бирәчәкмен.
Исраф булмас ул сүзләрең миндә,
Җыры булыр алар киләчәкнең.

Әйтә алмыйм әле: ул сүзләрдән
Аз булса да дөнья үзгәрерме?
Тик югалтмам, туган телем, синнән
Алып торган асыл сүзләремне.

Р. Миңнуллин

1. ***затлы*** сүзенә фонетик һәм лексик анализ ясагыз. **(10 балл)**

Фонетик анализ: (**6 балл:** ***һәр авазга 1 балл, иҗекләргә дөрес бүлеп, басымны дөрес билгеләгәнгә 0,5 балл, хәреф, аваз санын дөрес билгеләгәнгә 0,5 балл***)

зат-лы [за°т-лы́]

[з] – парлы яңгырау, саңгырау пары [с], өрелмәле, тел алды, авыз тартыгы;

[а°] – арткы рәт, түбән күтәрелешле, иренләшмәгән, озын сузык аваз;

[т] – парлы саңгырау, яңгырау пары [д], йомык, тел алды, авыз тартыгы;

[л] – парсыз яңгырау, ярымйомык, тел алды, авыз тартыгы;

[ы] – арткы рәт, урта күтәрелешле, иренләшмәгән,кыска сузык аваз.

---

5 хәреф, 5 аваз.

**Лексик анализ (4 балл)**

Затлы

1) Күп мәгънәле сүз: яхшы нәсел дип саналган; яхшы тәрбия алган, тәрбияле, эчке культуралы; яхшы токымлы (хайваннар, кошлар тур.); кыйммәтле һ.б. ***(1 балл)***

Күчерелмә мәгънәдә. ***(0,5 балл)***

Синонимы: затлы – асыл, кыйммәтле ***(0,5 балл)***

антоним – затсыз, начар, омонимы юк. ***(0,5 балл)***

2) Килеп чыгышы ягыннан – гарәп сүзе. ***(0,5 балл)***

3) Кулланылыш өлкәсе ягыннан – гомумхалык сүзе. ***(0,5 балл)***

4) Актив сүз. ***(0,5 балл)***

2. Тексттан фразеологизмны табып, мәгънәсен аңлатыгыз. **(2 балл)**

*Күз карасы кебек (саклау) – бик кадерләп, игътибар белән (саклау).*

3. ***Сүзләрем, бирәчәкмен, асыл*** сүзләренә морфологик анализ ясагыз. **(6 балл)**

*сүзләрем* – уртаклык исем, күплек санда, 1 зат берлек сандагы тартым белән төрләнгән, баш килештә, тамыр сүз, җөмләдә ия булып килгән. ***(2 балл)***

*бирәчәкмен* – хикәя фигыль, затланышлы, барлыкта, билгеле киләчәк заманда, 1 зат берлек санда, тамыр сүз, җөмләдә хәбәр булып килгән. ***(2 балл)***

*асыл* (сүзләр) – сыйфат, гади дәрәҗәдә, *сүзләр* сүзен ачыклаган, ясалышы ягыннан тамыр сүз. ***(2 балл)***

4. *Исраф булмас* сүзенең синонимын языгыз. **(1 балл)**

Әрәм-шәрәм ителмәс

5. *“Туган телемдәге асыл сүзләр”* темасына 10 җөмләдән торган бәйләнешле текст төзеп языгыз. **(10 балл)**

**Татар телендә гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры биремнәре *җаваплары***
**2021-2022 нче уку елы**
**10 нчы сыйныф**

**Максималь балл – 63**

## I. Гамәли бирем (37 балл)

Кемдер мактый язны, кемдер гашыйк җәйгә, өченчеләр ярата көзне.

Ә кыш үзенчә, башкача ямьле. Холкы да үзгәрүчән. Бер карауда – чытлы кыз ул. Кояш нурлары астында энҗе кар бөртекләрен җемелдәтә-җемелдәтә, көзгеләрдән карап керфекләрен ап-ак итеп буяп куя. Кардан такыялар үрә дә агач-кызыкайларның башларына тезеп куя. Ап-ак төстәге сырлап үрелгән, дөньяда бер модельер да тегә алмаган, күлмәкләр белән матурлый ул аларны. Хәйран гына чибәрләнә дә, шунда ук күз тиеп куя үзенә.

Киреләнә башлый. Сызгыра-сызгыра җил дустын чакыра. Йомшак кына яткан урыныннан йолкып уята да, өрдереп кар бөртекләрен әллә кайларга алып китә, күрмәгәннәрен күрсәтә. Кышкы “җаяүле буран” уены башлана. Чаптыра-чаптыра җил карны: таулар ясый, юлларны каплый. Җиһанны кар тигезли.

1. Тексттан басым соңгы иҗеккә төшмәгән сүзләрне күчереп языгыз. (**6 балл**)

*кемдер, үзенчә, башкача, ап-ак, алмаган, күрмәгәннәрен*

2. Тексттан күтәрелмә дифтонглар кергән 5 сүз күчереп языгыз. (**5 балл**)

*ярата, ямьле, кояш, буяп, куя*

3. Тексттан төшерелмә дифтонглар кергән 5 сүзе күчереп языгыз. (**5 балл**)

*мактый, гашыйк, җәйгә, агач-кызыкайларның, матурлый*

4. Тексттан сингармонизм законына буйсынмаган сүзләрне күчереп языгыз. **(4 балл)**

*дөньяда, модельер, хәйран, җиһанны*

5. *Төс* сүзеннән яңа сүзләр ясап языгыз. **(3 балл)**

*төсле, төссез, төстәге һ.*б.

6. Дөнья сүзенең мәгънәләрен языгыз. **(6 балл)**

1) галәм 2) Җир шары 3) чолгап тора торган барлык табигать, тирәлек 4) Кешелек җәмгыяте 5) тормыш, яшәеш, көнкүреш 6) бик күп

7. “Җәяүле буран” сүзтезмәсенең мәгънәсен аңлатып языгыз. **(1 балл)**

Җәяүле буран вакытында яңа яуган кар бөртекләре кар капламы өстеннән 1,5-2 м га кадәр җиңелчә күтәрелә.

8. Җөмлә кисәкләренең асларына сызыгыз, аларның кайсы сүз төркеме белән белдерелүләрен языгыз. Җөмлә төрен билгеләгез. (**6 балл: һәр җөмлә кисәген, аның кайсы сүз төркеме белән белдерелүен билгеләүгә – 0,5 б., җөмлә төрен билгеләгәнгә – 1,5 б.**)

*алм. хик. фиг. ис. алм. хик. фиг. ис. сан. хик. фиг. ис.*

*Кемдер мактый язны, кемдер гашыйк җәйгә, өченчеләр ярата көзне.*

теркәгечсез тезмә кушма җөмлә

9. *Кардан такыялар үрә дә агач-кызыкайларның башларына тезеп куя* җөмләсенең төрен билгеләгез. **(1 балл)** Гади җөмлә

## II. Теоретик бирем. (6 балл)

Татар теленең диалектларын, аларга хас үзенчәлекләрне языгыз. Һәр диалектка хас булган диалекталь сүзләргә бишәр мисал китерегез.

Телнең аерым бер төбәктә генә таралган төрен диалект дип атыйлар.

Татар телендә өч диалект бар:

1) урта диалект (Казан арты сөйләшләре);

2) көнбатыш диалект (мишәр сөйләшләре);

3) көнчыгыш диалект (Себер татарлары сөйләшләре).

Диалектлар сөйләшләргә бүленә. Урта диалект, мәсәлән, 12 сөйләштән тора. Бу сөйләшләр, зур территориягә таралган булсалар да, төп үзенчәлекләре белән үзара берләшәләр.

Урта диалектның кайбер үзенчәлекләре:

1) җ-ләштерү: җул, җегет.

2) [к], [г] авазларының калын әйтелеше: [к]арга, [к]амыш;

3) [а] авазының о-лаштырылуы: ба°ла°лар.

4) х//к күчеше: катын;

5) инфинитив формасы -мага, -малы: бармалы.

Көнбатыш диалектның кайбер үзенчәлекләре:

1) й-ләштерү: Йамали, йаңы;

2) [а] авазының ачык итеп әйтелүе: бала;

3) ирен-ирен [о], [ө], [у], [ү] иренсезләштерү: кен, беген, тен, кыяш;

4) дифтонгларны монофтонглаштыру: сүләү, әдә, ү, бәрәм;

5) [к], [ғ] авазларының [к], [г] булып әйтелүе яисә төшеп калуы: кар, афу.

Көнчыгыш диалектның кайбер үзенчәлекләре:

1) ц-лаштыру: пыцак, бырцак;

2) [б], [д], [з] тартык авазларының саңгырау парларына алмашынуы: Пыел урашай полса ярар иде.

**III. Иҗади бирем. (20 балл)**

“Модельер булам әле” темасына 15-20 җөмләдән торган текст төзеп языгыз. Текстыгызда иярченле һәм тезмә кушма җөмләләр дә кулланыгыз (икешәрне). **(20 балл)**

**Татар телендә гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры биремнәре *җаваплары* 2021-2022 нче уку елы 11 нче сыйныф**

**Максималь балл – 60**

**II. Гамәли бирем (29 балл)**

Салихны «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә биргәннәр иде, ул бик тырышып шунда белем эстәде. Бу атаклы мәдрәсәдә Кәрим Тинчурин, Фатих Әмирхан кебек асыл затларның укып чыгуын белгәч, горурлыктан малайның башы күккә тиде. Алар бит икесе дә Салих яшәгән өйдә, дөресрәге, икенче җизнәсе Шиһаб Әхмәров йортында бик еш кунак булалар. Театр, әдәбият-сәнгать турында озаклап гәпләшәләр, уен-көлкеле сүзләр чыктымы, шаулатып көләләр. Ике Габдулла – Кариев белән Тукай – йөзек кашыдай, мәҗлес күрке.

Салих һәммәсен игътибар белән тыңларга тырыша. Шушындый мөхтәрәм кунаклар барында үзеңне «зур кеше» шикеллерәк хис итми кара син!

Рашат Низамидан

10. Сүзләрнең синонимнарын языгыз:

белем эстәде, (мәҗлес) күрке, мөхтәрәм, гәпләшәләр, атаклы (**5 балл**)

белем эстәде – белем алды, укыды

(мәҗлес) күрке – мәҗлес яме

мөхтәрәм – хөрмәтле

гәпләшәләр – сөйләшәләр

атаклы – күренекле

11. *Җизни* сүзе нинди туганлык мөнәсәбәтен белдерә? (**2 балл**)

Җизни – үзеңнән зур кыз туганның ире

12. Тексттан биш алмашлык күчереп языгыз, төркемчәләрен билгеләгез.

(**5 балл**)

ул – зат алмашлыгы

бу – күрсәтү алмашлыгы

алар – зат алмашлыгы

һәммәсе – билгеләү алмашлыгы

үзеңне – билгеләү алмашлыгы

син – зат алмашлыгы һ.б.

13. Затланышсыз фигыльләрне күчереп языгыз, төркемчәләрен билгеләгез.

(**5 балл:** һәр дөрес җавапка 0,5 б.)

тырышып (хәл ф.), укып (хәл ф.), чыгуын (исем ф.), белгәч (хәл ф.), үсеп (хәл ф.), яшәгән (сыйфат ф.), озаклап (хәл ф.), шаулатып (хәл ф.), тыңларга (инфинитив), хис итми (хәл ф.)


14. *башы күккә тию* фразеологизмының мәгънәсен аңлатып языгыз.

**(1 балл)**

бик нык шатлану

15. *Салихны «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә биргәннәр иде, ул бик тырышып шунда белем эстәде* җөмләсенә синтаксик анализ ясагыз. **(5 балл)**

1) *Салихны «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә биргәннәр иде*, 2) *ул бик тырышып шунда белем эстәде.*




Бу - аналитик иярчен урын җөмләле кушма җөмлә.

16. *Бу атаклы мәдрәсәдә Кәрим Тинчурин, Фатих Әмирхан кебек асыл затларның укып чыгуын белгәч, горурлыктан малайның башы күккә тиде* җөмләсенең төрен, компонентларның чикләрен, бәйләүче чараны билгеләгез.

**(3 балл)**

1) *Бу атаклы мәдрәсәдә Кәрим Тинчурин, Фатих Әмирхан кебек асыл затларның укып чыгуын белгәч,* 2) *горурлыктан малайның башы күккә тиде.*

Бәйләүче чара -гәч хәл фигыль кушымчасы.

*Бу* – синтетик иярчен вакыт җөмләле кушма җөмлә.

17. Сүзләргә морфологик анализ ясагыз. **(3 балл)**

*Гәпләшәләр, кашыдай, уен-көлке*

*гәпләшәләр* – хикәя фигыль, затланышлы, барлыкта, хәзерге заманда, III зат күплек санда, ясалма сүз.

*кашыдай* – охшату-чагыштыру рәвеше, ясалма сүз.

*уен-көлке* – уртаклык исем, берлек санда, тартым белән төрләнмәгән, баш килештә, парлы сүз.

## II. Теоретик бирем. (6 балл)

Җөмләнең баш кисәкләре турында, аларның кайсы сүз төркемнәре белән белдерлүләрен аңлатыр язып языгыз. Өч гади җөмлә мисалында аңлатыгыз.

Ия белән хәбәр җөмләнең баш кисәкләре дип атала. Баш кисәкләр җөмләнең грамматик нигезен барлыкка китерә. Башка сүзләргә буйсынмый торган баш кисәк ия дип атала. Хәбәр – ия турында хәбәр итә, аңа ияреп килә торган баш кисәк.

Ия дә, хәбәр дә төрле сүз төркемнәре (исем, алмашлык, сыйфат, сан, рәвеш, фигыль) белән белдерелә ала. Фигыльдән башка сүз төркеме (исем, алмашлык, сыйфат, сан, рәвеш) белән белдерелгән хәбәр исем хәбәр дип атала.

ис. ис.
Акбай – безнең яраткан эт.
алм. фиг.
Мин аны ашатам.
сыйф. ис.
Соры – матур төс.

## III. Иҗади бирем. (25 балл)

Тукай терелгән, ди. Һәм сезгә аның белән очрашу мөмкинлеге бирелгән икән. Шул кыска гына вакыт эчендә бөек шагыйребезгә нәрсә турында сөйләр, аңарга нинди сораулар бирер идең?

“Тукай белән очрашу” темасына 20-25 җөмләдән торган текст төзеп языгыз.